**ГЛАВА**
**Салаушского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Салагыш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д.73 а, с. Салауши, Агрызский район, 422214
Ленин ур., 73 а, Салагыш авылы, Әгерҗе районы, 42221

**Тел.: (85551) 3-74-38, Факс: 3-74-34. E-mail: Salaush.Agr@tatar.ru; www.agryz.tatarstan.ru**

24.11.2020 Салагыш авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 07 декабрендә 12 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 350 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Ямурза урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу).

2. Ямурза авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

3. Ямурза авылы территориясендә су насослары, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу,;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Ямурза авылы, Елга урамы, 23А йорт, авыл клубы адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.М.МӨХӘММӘДИЕВ